# КАРАР

**24 ноябрь 2023 ел** **№3**

**Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Түбән Үрәс авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 24 ноябрендә 2 этапта түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

« Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Түбән Үрәс авыл җирлеге Түбән Үрәс авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан; 1 төркем инвалидларыннан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1300 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- янгын сүндерү машинасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);
- *урамны яктыртуны карап тоту (энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус* җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Түбән Үрәс авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- ТүбәнҮрәс авылындагы сүүткәргеч челтәрен һәм су башнясын (ВНБ) ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү; (материаллар сатып алу һәм урнаштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);
- Түбән Русь авылында 1 Май һәм Березовая урамнары буенча юлларны чокырлы ремонтлау; проект - смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру;
- янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру (материаллар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү; проект - смета документациясе);
- Түбән Урәс авылын төзекләндерү, чишмәне тоту, проект-смета документациясе, технадзорны гамәлгә ашыру, материалны сатып алу, ташу һәм чишмәне төзекләндерү һәм тоту буенча башка эш төрләре

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 136 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 75 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 75 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Түбән Үрәс авылында халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: « Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Түбән Үрәс авыл җирлеге Түбән Үрәс авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан; 1 төркем инвалидларыннан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1300 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- янгын сүндерү машинасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);
- урамны яктыртуны карап тоту (энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Түбән Үрәс авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- ТүбәнҮрәс авылындагы суүткәргеч челтәрен һәм су башнясын (ВНБ) ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү; (материаллар сатып алу һәм урнаштыру, су башнясына буяу алу һәм буяу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру) ;
- Түбән Үрәс авылы территориясен төзекләндерү (чүп-чарны һәм агачларны чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);
-Түбән Русь авылында 1 Май һәм Березовая урамнары буенча юлларны чокырлы ремонтлау; проект - смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру;
- янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру (материаллар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү; проект - смета документациясе);
-Түбән Урәс авылын төзекләндерү, чишмәне тоту, проект-смета документациясе, технадзорны гамәлгә ашыру, материалны сатып алу, ташу һәм чишмәне төзекләндерү һәм тоту буенча башка эш төрләре

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Түбән Үрәс
авыл җирлеге башлыгы В.Г.Сафаров

ОГРН 1021607753133
ИНН 1623002015